ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Зеленодольск** **КАРАР**
**26.08.2026** **шәһәре** **№ 2966**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан торак урыннарны, торак урыннарны яшәү өчен яраклы яисә яраксыз дип тану максатларында, күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урынны – торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле , торак йортны бакча йорты, бакча йортын торак йорт дип тану турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан торак урыннарны, торак урыннарны яшәү өчен яраклы яисә яраксыз дип тану максатларында, күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия комиссия төзергә.

2.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан торак урыннарны, торак урыннарны яшәү өчен яраклы яисә яраксыз дип тану максатларында, күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү мәсьәләләре буенча ведомствоара составын 1 нче кушымтада каралганча расларга.

3. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан торак урыннарны, торак урыннарны яшәү өчен яраклы яисә яраксыз дип тану максатларында, күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында» нигезләмәне 2 нче кушымтада каралганча расларга.

4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы

территориясендә урнашкан торак урыннарны, торак урыннарны гражданнарга яшәү өчен яраклы яисә яраксыз дип тану максатларында, күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2026 елның 4 февралендәге 321 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җитәкчесе П.Н. Сергеевка йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты тарафыннан
2026 елның 26 августындагы
2966 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы
территориясендә урнашкан торак урыннарны,
торак урыннарны яшәү өчен яраклы яисә яраксыз дип тану максатларында,
күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә
реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында торак урыннарны бәяләү
һәм тикшерү мәсьәләләре буенча ведомствоара
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Хәбибуллин З. Ф. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, **комиссия рәисе** |
| Сергеев П.Н. | «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ җитәкчесе, **комиссия рәисе урынбасары** |
| Левочкина Н.Н. | «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ генераль план, кызыл сызыклар, топография, геология һәм инженер коммуникацияләре бүлеге начальнигы, **комиссия секретаре** |
| **Комиссия әгъзалары:** | |
| Матвеева О.А. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Зиннуров Р.Н. | «Зеленодольск муниципаль районы техник күзәтү хезмәте» ҖЧҖ директоры (килешү буенча) |
| Ганеева Е.К. | Татарстан Республикасы буенча кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте идарәсенең Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнары территориаль бүлеге начальнигы(килешү буенча) |
| Батуева С.Ф. | «Татарстан Республикасының (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБУЗның Зеленодольск филиалы баш табибы (килешү буенча) |
| Шакшин А.Е. | «Зеленодольск муниципаль районы торак сәясәте департаменты » МКУ җитәкчесе |
| Бакиров Р.Ф. | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең үзәк территориаль инспекторлык идарәсе начальнигы (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты тарафыннан
2026 елның 26 августындагы
2966 номерлы карарына
2 нче кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ УРНАШКАН ТОРАК УРЫННАРНЫ, ТОРАК УРЫННАРНЫ ЯШӘҮ ӨЧЕН ЯРАКЛЫ ЯИСӘ ЯРАКСЫЗ ДИП ТАНУ МАКСАТЛАРЫНДА, КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТЛАРНЫ АВАРИЯ ХӘЛЕНДӘ ҺӘМ СҮТЕЛЕРГӘ ЯИСӘ РЕКОНСТРУКЦИЯЛӘНЕРГӘ ТИЕШЛЕ ДИП ТАНУ МАКСАТЛАРЫНДА ТОРАК УРЫННАРНЫ БӘЯЛӘҮ ҺӘМ ТИКШЕРҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ БУЕНЧА ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯ ТУРЫНДА**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Нигезләмә гамәлдәге законнар нигезендә эшләнгән һәм торак урыннарны, торак урыннарны яшәү өчен яраклы яисә яраксыз дип тану максатларында, күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия эшен регламентлаштыра торган мәсьәләләрне билгели. (алга таба – Комиссия).

1.2. Комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Торак кодексына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урынны – торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле , торак йортны бакча йорты, бакча йортын торак йорт дип тану турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карарына, муниципаль хокукый актларга һәм әлеге Нигезләмәмгә таяна.

## 2. КОМИССИЯНЕҢ ТӨП БУРЫЧЛАРЫ

Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- торак урыннарның даими яшәү өчен яраклылыгын яки яраксызлыгын бәяләү буенча эшләр үткәрү;
- урыннарны торак урыннар, торак урыннарны яшәү өчен яраклы яисә яраксыз дип тану турында, күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында карарлар кабул итү.

## 3. КОМИССИЯНЕҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен түбәндәге хокукларга ия:

- Комиссия компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә кирәкле мәгълүматны сорарга;
- Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча үз утырышларында дәүләт контроль (күзәтчелек) органнары вәкилләрен, физик һәм юридик затларны тыңларга;
- Комиссия утырышына кызыксынучы якларны, өстәмә экспертларны, эшчәнлек өлкәсенә торак урыннарның техник торышын билгеләү белән бәйле мәсьәләләр кергән төрле оешма һәм учреждение вәкилләрен чакыртырга;

- Комиссиянең компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе каравына тәкъдимнәр кертергә.

## 4. КОМИССИЯНЕҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

4.1. Комиссия составына рәис, рәис урынбасары, секретарь, Комиссия әгъзалары керә. Комиссия рекомендацияләр бирү өчен техник экспертларны, проектлаучы оешмаларны вәкилләрен һәм башка белгечләрне җәлеп итәргә хокуклы.

4.2. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма аена кимендә 1 тапкыр уздырыла. Комиссиянең чираттагы утырышын уздыру турындагы карар, тапшырылган документларны исәпкә алып, Комиссия рәисе тарафыннан кабул ителә.

4.3.Комиссия урынның гамәлдәге законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяли һәм торак урынны яшәү өчен яраклы яисә яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында карар чыгара.

4.4. Комиссиягә карар кабул итү өчен торак урынны гамәлдәге законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килә яисә туры килми дип тану турында карар кабул итү өчен кирәкле өстәмә документлар тапшыру кирәк булган очракта, Комиссия өстәмә документлар таләп итү максатыннан утырышны кичектереп тору турында карар кабул итәргә хокуклы.

4.5. Әгәр Комиссия карарын кабул итү өчен өстәмә тикшерүләр яки сынаулар үткәрү кирәк булса, Комиссия аларны үткәрү турында карар кабул итә ала. Тикшерү нәтиҗәләре буенча урынны тикшерү акты төзелә.

4.6. Комиссия эше нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- урынның торак урынга куела торган таләпләргә туры килүе, аның яшәү өчен яраклылыгы турында;
- торак урынның эксплуатацияләү процессында югалтылган характеристикаларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан - капиталь ремонт, реконструкция яки яңадан планлаштыру (кирәк булганда, техник-икътисадый нигезләү белән) кирәклеге һәм мөмкинлеге турында һәм алар тәмамланганнан соң - бәяләү процедурасын дәвам итү турында;
- урынның яшәү өчен яраксыз дип танылу нигезләрен күрсәтеп, урынның торак урынга куелган таләпләргә туры килмәве турында;
- күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану турында.

## 5. Комиссиянең җаваплылыгы

Комиссия әгъзалары гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә җаваплы.